**Халкыбызның асыл заты**

16 январь көнне Бәзәкә китапханәсендә галим-фәлсәфәче, әдип, дин әһеле, җәмәгать эшлеклесе Р.Фәхреддиннең тууына 160 ел тулу уңаеннан “Халкыбызның асыл заты” дип исемләнгән тематик кичә узды. Кичәдә катнашучылар аның тәрҗемәи хәле белән видео аша таныштылар, китапханәче Ф.Башарова “Риза Фәхреддин - олуг фикер иясе һәм мәгърифәт әйдаманы” дигән китап киштәсендәге китапларга күзәтү ясады, укучылар А.Нуретдинова, З.Гыйльметдинова, Р.Мусина тәрбия, әдәп-әхлак мәсьәләләренә багышлап язылган “Нәсыйхәт” китабына аерым тукталып ир һәм кыз балаларны рухи тәрбияләүгә, үз-үзеңне тоту кагыйдәләренә өйрәтә торган бүлекләрдән өзекләр укыдылар, абыстай М.Исмагилова ислам дине турындагы “Җәвамигуль – Кәлим» шәрехе” китабына аңлатмалар бирде.
Милләтебезгә риясыз хезмәт иткән, Болгар чорыннан алып XX-нче йөз башларынача Русиядәге мәшһүр ислам галимнәре һәм дәүләт эшлеклеләренең, аларның шәкертләренең тормышы һәм эшчәнлеге тасвирләнган “Асар” (Эзләр) китабын язган галим Ризаэтдин Фәхреддин турында кичәдә катнашучылар киң мәгълүмат алып киттеләр.




БАЛАЧАК
2019-1-16 12:54


Риза Фәхреддин –
олуг фикер иясе
һәм мәгърифәт
айдамы
2019-1-16 13:10


2019-1-16 13:15


2019-1-16 13:27